## 2нче февраль - Россиядә Хәрби дан көне

2нче февраль - Россиядә Хәрби дан көне, немец-фашист гаскәрләрен Сталинград шәһәре янында тар-мар иткән көн буларак искә алына.1943нче елның февраль аенда Сталинград астында барган канкойгыч бәрелешләрдә Совет Кызыл Армиясе фашист гаскәрләрен чигенергә мәҗбүр итә, шәһәр тулысынча фашист камалышыннан азат ителә. 1942нче елның 17нче июленнән 1943нче елның 2нче февраленә кадәр, ике чорга бүленеп, бертуктаусыз дәвам иткән әлеге коточкыч бәрелешләр вакытында ике яктан да 2 миллионнан күбрәк кеше һәлак була. Һәр урам, һәр йорт өчен барган сугышта Сталинградның вокзал бинасы гына да 13 тапкыр кулдан-кулга күчә, шәһәр тулысынча җимерелә, хәрабәләргә әверелә. Сталинград астындагы җиңүдән соң, Бөек Ватан сугышында гына түгел, Икенче бөтендөнья сугышында да тамырдан борылыш башлана. Шушы бәрелештә Совет Кызыл Армиясенең өстенлекле калуы, җиңүгә ышанычны ныгыта. Сталинград афәтен үз башларыннан кичергән солдатлар арасында районадашларыбыз да булган. Дошман тырнагыннан безгә дигән тынычлыкны үз гомерләре хисабына яулап алучы каһарманнар батырлыгы тиңдәшсез. Ил иминлеге бәрелеш-сугышлар белән әле дә сынала. Күкләребез тыныч булсын, сугыш афәтләре, хәсрәтләрдән ерак торсак иде.

